ГОСУДАРСТВЕННЫЙ
КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.12.2025 г.Казань № 714-225/кс-2025

2026 елга Казан шәһәренең «Казан сөт комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 19.12.2025 ел, №35-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына туры китереп, кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы Казан шәһәренең «Казан сөт комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «Казан сөт комбинаты» ЖЧЖ) өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында җиткерелә торган кайнар суга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

4. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы Казан шәһәренең «Казан сөт комбинаты» ЖЧЖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат

ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
19.12.2025 № 714-225/кс-2025
карарына кушымта

Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Казан сөт комбинаты» ЖЧЖ тарафыннан кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга 2026 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Кайнар су белән тәэмин итүче оешма, муниципаль берәмлек исеме | Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тариф (бер компонентлы), сум/куб.м | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | изоляцияләнгән торбалар белән | | изоляцияләнмәгән торбалар белән | | изоляцияләнгән торбалар белән | | изоляцияләнмәгән торбалар белән | |
| | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | |
| | | әйе | юк | әйе | юк | әйе | юк | әйе | юк |
| | | 01.01.2026 башлап 30.09.2026 кадәр | | | | 01.10.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | | | |
| | Казан шәһәре | | | | | | | | |
| 1 | «Казан сөт комбинаты» ЖЧЖ | | | | | | | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелә)* | 177,64 | 166,70 | 190,77 | 179,39 | 192,06 | 180,56 | 205,89 | 193,91 |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 145,61 | 136,64 | 156,37 | 147,04 | 157,43 | 148,00 | 168,76 | 158,94 |

* Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын үтәү максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге